СОВЕТ СРЕДНЕКИРМЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Ленина, д.16А, с. Средние Кирмени, Мамадышский район, Республика Татарстан. 422171

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УРТА КИРМӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Ленин ур., 16А нчы йорт, Урта Кирмән авылы, Мамадыш районы, Татарстан Республикасы,422171

тел.(факс): (85563) 2-92-38;2-92-44 e-mail: Skimer.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение — Карар

№ 4-8 — «13» апрель 2016 ел

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр, шулай ук Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Урта Кирмән авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 73-ФЗ номерлы, 2012 елның 3 декабрендәге «Дәүләт Вазыйфаларын биләүче затлар һәм аларның керемнәренә башка затлар чыгымнарының туры килүен тикшереп тору турында» 230-ФЗ номерлы федераль законнар, Россия Федерациясе Президентының 2013 елның 08 июлендәге 613 номерлы «Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре» указы, «Россия Федерациясе Президентының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмә формаларын раслау турында» 2014 елның 23 июнендәге 460 номерлы Указы, «Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакында» Указына үзгәрешләр кертү турында» 2013 елның 22 апрелендәге ПУ-330 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Урта Кирмән авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Түбәндәгеләрне расларга:

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Урта Кирмән авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы

гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Урта Кирмән авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында нигезләмәне (1 нче кушымта);

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлегендә гражданнар билгеләгәндә үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр , керемнәре, чыгымнары, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында мәгълүмат, шулай ук керемнәр турында мәгълүмат тапшырырга, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләре турында тапшырырга тиешле муниципаль вазыйфалар исемлеге (2 нче кушымта).

2. Мамадыш муниципаль районының Урта Кирмән авыл җирлеге Советының 2014 елның 19 ноябрендәге «Мамадыш муниципаль районының Урта Кирмән авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр, шулай ук Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакында нигезләмәне раслау турында» 5-35 номерлы карарын үз көчен югалтты дип танырга.

3. Карарны Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге башлыгы Б.Ф.Хәсәновка йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Урта Кирмән авыл җирлеге башлыгы,
авыл җирлеге Советы рәисе Б.Ф.Хәсәнов